БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
10 март 2026 ел

**КАРАР**
№37

**«Татарстан Республикасы Балтач район Советының закон чыгару инициативасы турында» 2026 елның 3 февралендәге 35 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәреш кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясының 1 өлеше, «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13, 19 статьялары нигезендә, «Балтач шәһәр тибындагы поселогы», «Сосна авыл җирлеге» һәм «Норма авыл җирлеге» чикләрен үзгәртү, шулай ук «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Куныр авыл җирлеге», «Нөнәгәр авыл җирлеге», «Пыжмара авыл җирлеге», «Смәел авыл җирлеге», «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен Киров өлкәсе белән чиктәш Татарстан Республикасы чигенә туры китерү турында мәсьәләсе буенча җирлекләрдә яшәүчеләрнең муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан белдерелгән ризалыгын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Балтач район Советының закон чыгару инициативасы турында» 2026 елның 3 февралендәге 35 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына «Татарстан Республикасы Балтач районының Ямбурово поселогын бетерү, аерым муниципаль берәмлекләрнең территория чикләрен үзгәртү һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территория чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законы проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин